МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

03.06.2019 г.Казань № 421

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 10 июлендә 5685 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелекне һәм контрольне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июлендәге 592 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелекне һәм контрольне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июлендәге 592 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 11.01.2013 № 5, 25.09.2014 № 518, 02.06.2015 № 366, 02.07.2016 № 377, 02.05.2017 № 269, 27.12.2018 № 1150 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән
тәэмин итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2019 елның
«03» июнендәге 421 номерлы
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелекне һәм контрольне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июлендәге 592 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелекне һәм контрольне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 25 июлендәге 592 номерлы боерыгында (алга таба – боерык):

боерыкның исемендә «билгеләнгән квота чикләрендә» сүзләреннән соң «тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән» сүзләрен өстәргә;

1 пунктта «билгеләнгән квота чикләрендә» сүзләреннән соң «тикшерүләр үткәрү, үтәү өчен мәҗбүри булган күрсәтмәләр бирү һәм беркетмәләр төзү хокукы белән» сүзләрен өстәргә;

боерык белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының билгеләнгән квота чикләрендә инвалидларны эшкә алуга күзәтчелекне һәм контрольне гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентында:

1.7 пунктның 9 пунктчасын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«9) ачыкланган бозу фактлары буенча күреләчәк чараларны билгеләгәндә күрсәтелгән чараларның бозуларның авырлыгына, аларның кешеләрнең гомере, сәламәтлеге өчен потенциаль хәтәренә туры килүен исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре нигезсез рәвештә чикләнүгә юл куймаска;»;

2.16 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәрге чорда үзләре турында белешмәләр кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрына кертелгән, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законның 4

статьясындагы нигезләмәләргә ярашлы нигездә кече эшкуарлык субъектларына кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр 294-ФЗ номерлы федераль законның 26.2 статьясындагы таләпләргә ярашлы рәвештә оештырыла һәм үткәрелә.»;

2.18 пунктның 2 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2) Министрлыкка гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан кулланучыларның хокуклары бозылу фактлары турында мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан мәгълүматлар килү.».